КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 март г.Казань № 181

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 һәм 2024 елларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле капиталь булмаган чараларын булдыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү һәм (яисә) каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 8 декабрь, 1594 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 һәм 2024 елларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле капиталь булмаган чараларын булдыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү һәм (яисә) каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 8 декабрь, 1594 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада татар текстында тиешле килешләрдәге «дәүләт программасы» сүзләре алдына тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2023 һәм 2024 елларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан

Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле капиталь булмаган чараларын булдыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү һәм (яисә) каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин